ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.7, пос. Октябрьский, 422580

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 7 нче йорт, Октябржский авылы, 422580

Тел.: (84379) 31-4-27, факс: (84379) 31-4-27.

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Матюшино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№1 27.11.2021

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 27 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге мәсьәлә буенча беркетмә төзелде :
"Сез 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Матюшино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:
- Матюшино авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау
Халык җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 63 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 46 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 46 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Матюшино авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.
2. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Матюшино авылында 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районы Матюшино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?:

Матюшино авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау

3. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Матюшино авылы гражданнарының җыены нәтиҗәләрен Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен әлеге карарны җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Ш.Р. Азизов